ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№_029_ «_22_» ___03___ 2017 ел

Газпром трансгаз Казан» ЖЧЖ
«Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районының Берсут т.п. да
ГГРПны техник җиһазлау» линияле
объектын төзү территориясен планлаштыру
һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар
уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы, Мамадыш районында 2012 елның 10 сентябрендәге 6-15 номерлы Гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Газпром трансгаз Казан» ЖЧЖ «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Берсут т.п. да ГГРПны техник җиһазлау» линияле объектын төзү территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлауларны уздырырга (1 нче кушымта).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Гавами тыңлауларны уздыру вакыты - 2017 елның 21 апреле, сәг. 10:00;

2.2. Уздыру урыны – Мамадыш шәһәре, М. Җәлил урамы, 23/33 йорт адресы буенча урнашкан Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы;

2.3. Гавами тыңлауларда чыгыш хокукы белән катнашуга һәм фикер алышкан мәсьәлә буенча тәкъдимнәрне тбәндәге адрес буенча бирергә мөмкин: ТР, Мамадыш районы, Мамадыш шәһәре, М. Җәлил урамы, 23/33 йорт (эш көннәрендә – 8:00 - 16:00 кадәр)

2.4. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү вакыт – 2017 елның 20 апреленә кадәр (3-28-74)

3. Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән әлеге мәсьәлә буенча билгеләнгән тәртип һәм билгеләнгән вакытта гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

4. 2017 елның 23 мартына кадәр әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http:mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район
Башлыгы А.П. Иванов